# ЧИШМӘ БАШЫ




Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «МӨНДЕШ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ» МБМББУ,
сентябрь, 2025 ел № 8

***Ата-аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы***

***Газетаның сәхифәләре:***

1. ***Күрәмсез, дуслар! Көз килде тышта.***
2. ***Иҗади бәйге уңышлары.***
3. ***Көз турында сынамышлар, шигырь***
4. ***«Көз безгә нәрсә алып килде?» (шөгыль)***

**Баш мөхәррир:**
**балалар бакчасы мөдире**
**Мостафина Рима Галип кызы.**
**Мөхәррир урынбасарлары:**
**музыка җитәкчесе Хөсәенова Г.Ф.**
**тәрбиячеләр: Хөсәенова Р.Р.,**
**Җәләлиева А.Г., Шәкүрова Р.С.**

***Күрәмсез, дусларым, көз килде тышта.***
***Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.***
***Китә башлады бездән инде бездән кошлар.***
***Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.***

Көз – табигатьнең иң матур, иң асыл вакыты. Тирә-як, әйтерсең, алтынга күмелә. Әлеге матурлыкны күрми калмыйк дип, Мөндеш балалар бакчасында тәрбияләнүче балалар көзге табигатькә экскурсиягә чыктылар. Балалар өчен йөрү һәрвакыт кызыклы вакыйга бит. Балалар көзге табигать буенча сәяхәт иткәндә күпме мавыктыргыч, файдалы, кызыклы нәрсәләр белделәр.

Тәрбиячеләр көзге табигатьнең матурлыгына сокланырга әйдәде, һава, җир, кояш, үсемлекләргә игътибар итәргә өйрәттеләр. Балаларга саф һавада хәрәкәтле уеннар оештырылды. Соңыннан балалар “Куян күчтәнәчләре”ннән авыз иттеләр. Көзге табигатькә экскурсия балаларның күңелендә зур тәэсир калдырды.





# *Иҗади бәйге уңышлары.*

Безнең балалар бакчасы «Татар экиятләре һәм мультфильмнары геройлары» («Герои татарских сказок и мультфильмов») дип исемләнгән иҗади бәйгедә катнашты. Бәйге Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы мәгариф идарәсе планы нигезендә үткәрелде. Бәйгегә татар экияте, мультфильмнан рәсем ясап яки кул эшләнмәсе ясап ташырасы иде.

16 нчы сентябрьдә Арчаның 6 нчы номерлы балалар бакчасында бәйгегә нәтиҗә ясалды.

*Хисматуллина З. – 1 урын*

*Саляхов Д. – 2 урын*

*Закирова М. – 3 урын*

*Лотфуллин С. – 3 урын*

*Саляхов Р. – 3 урын*

*Набиуллина Р. – актив катнашучы.*

Катнашучы балаларга һәм аларның әти-әниләренә зур рәхмәтебезне белдерәбез. Алдагы бәйгеләрдә дә актив катнашып җиңү яулауларын теләп калабыз!






## *Көз турында сынамышлар*

- Көз озын килсә, яз соң килер.
- Пәрәвезләр күп очса, көз җылы, кыш салкын килер.
- Көзге көн бәс тотса, аязлыкка галәмәт.
- Имәндә чикләвек күп булса, кыш салкын килә.
- Чия яфраклары коелып бетми торып, кар күпме яуса да, эреп бетә.
- Кыр казлары иртә китсә, кыш иртә килә.
- Сентябрь җылы һәм коры булган саен, кыш соңрак килә.

## *Яфрак бәйрәме*

Яңгыр түгел, кар да түгел,
Яфраклар ява җиргә.
Көз турында җырлыймын мин —
Кушыл син яңа җырга.
Сары, сары, сап-сары
Агачның яфраклары.
Җил исә, ява яфрак —
Көзнең матур чаклары.
Оча яфрак, уйный яфрак
Һаваларда әйләнеп.
Бүген, бүген, бүген, бүген
Яфракларның бәйрәме!

Ләбиб Лерон

## ***Балалар белән әйләнә - тирә белән таныштыру эшчәнлегендә «Көз безгә нәрсә алып килде?» диган темага сөйләштек.***

Эшчәнлек барышында балалар яшелчә һәм җиләк - җимешләргә кагылышлы табышмаклар, әйтемнәр, сынамышлар, такмазаларга җавап бирделәр.

«Уңыш җыю» уенында җиләк - җимеш һәм яшелчәләрне кәрзиннәргә аерып тутырдылар.

Шулай ук яшелчәләрнең орлыктан алып яшелчә булып өлгерү схемасы белән таныштылар.

Балалар белән яшелчә һәм җиләк - җимешләрнең витаминнарга бай булуы һәм сәламәтлек өчен аларның бик файдалы булуы турында сөйләштек.







